УДК 811.512.145

***В.М. Гарипова-Хәсәншина***

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ЗАМАНЧА УКУ ӘСБАБЫ

## (Татарский: лёгкий, удобный, простой (Интенсивный курс): учебное пособие / М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2026. – 232 с. китабына бәяләмә)

В данной статье представлен анализ опыта разработки учебного пособия по татарскому языку, предназначенного для широкого круга пользователей, осваивающих его как неродной. Автор фокусируется на ключевых аспектах: структуре и системности изложения учебного материала, представленных моделях речевой практики, инструментарии для формирования навыков связной речи на татарском языке, а также на методике подачи лексико-грамматического материала. Кроме того, в статье освещается процесс создания современного учебника, ориентированного на интенсивное освоение татарского языка. По итогам анализа автор заключает, что учебное пособие, в основе которого лежит формирование коммуникативной компетенции, полностью соответствует современным педагогическим требованиям в части структуры и методики представления материала.

**Ключевые слова:** учебное пособие, татарский язык, коммуникативная компетенция, лексико-грамматический материал, связная речь, учебный материал

This article presents an analysis of the experience of developing a textbook on the Tatar language, which is intended for a wide range of users who are learning it as a non-native language. The author focuses on key aspects, such as the structure and systematic presentation of the educational material, the models of speech practice, the tools for developing the skills of coherent speech in the Tatar language, and the methodology for presenting lexical and grammatical material. Additionally, the article highlights the process of creating a modern textbook that focuses on intensive learning of the Tatar language. Based on the analysis, the author concludes that the textbook, which is based on the formation of communicative competence, fully meets modern pedagogical requirements in terms of its structure and presentation methods.

**Keywords:** textbook, Tatar language, communicative competence, lexical and grammatical material, coherent speech, educational material

Заман үзгәрешләре кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә үтеп керә, үзенең таләпләрен куя. Бу уку-укыту системасын да читләтеп үтми, билгеле. Соңгы елларда дөнья күргән күпсанлы дәреслекләр, методик ярдәмлекләр, төрле форматтагы сүзлекләр, уку әсбаплары – шуның ачык мисалы. «Заманча дәреслек, уку әсбабы нинди булырга тиеш?» дигән сорау хәзерге вакытта уку-укыту өлкәсендә иң актуаль мәсьәләләрдән санала. Шушы сорауга җавапларның берсе буларак, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән

«Татарский: легкий, удобный, простой (Интенсивный курс)» уку әсбабы дөнья күрде. Әлеге китап Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән нәшер ителгән.

Уку әсбабы татар телен чит тел буларак өйрәнүче киң катлам укучыларны күздә тотып эшләнгән. Ярдәмлекне телне мөстәкыйль өйрәнү өчен дә, шулай ук педагог белән дәресләрдә дә кулланырга мөмкин.

Китап авторлары фикеренчә, татар теленә өйрәтү процессы беренче адымнардан ук укучыларның аралашу сәләтен үстерүгә юнәлдерелергә тиеш [1: 3]. Бу фикер, ягъни телне өйрәнүчеләрдә коммуникатив компетенция формалаштыруга йөз тоту әлеге уку әсбабының нигезендә ята. Ул, үз чиратында, китапның гомуми структурасына, лексик-грамматик материалның бирелешенә, белем һәм күнекмәләр ныгыту өчен тәкъдим ителгән биремнәрнең эчтәлегенә тәэсир итә.

«Татарский: легкий, удобный, простой (Интенсивный курс)» китабы уку-укытуның төп эчтәлеген тәшкил иткән егерме дүрт дәрестән, белем һәм күнекмәләрне тикшерүне күздә тоткан гомуми йомгак ясау өлешеннән, «Татар теленең фонетикасы һәм графикасы», «Татар теле грамматикасы турында кыскача мәгълүмат» темаларын үз эченә алган кушымтадан, татарча-русча сүзлектән һәм көндәлек фразалар тупланмасыннан гыйбарәт. Эчтәлек өлеше татар һәм рус вариантларында тәкъдим ителгән. Бу, үз чиратында, тиешле теманы, материалны эзләп табуны күпкә җиңеләйтерә.

Әсбапта татар теленең фонетикасы, графикасы һәм грамматикасы турындагы кыскача материал, лексик темаларга корылган дәресләрдән аерып, кушымта итеп тәкъдим ителә. Телне үзлектән өйрәнүчеләргә китап белән эшне «Татар теленең фонетикасы һәм графикасы» [1: 172–177] өлеше белән танышудан башлау зарур. Әлеге кушымтада татар теленең тартыклар һәм сузыклар системасы, басым, сингармонизм мәсьәләләре карала.

Структурасы һәм эчтәлеге ягыннан дәресләр эзлекле, билгеле бер калыпка салынган. «Исәнләшү. Танышу. Саубуллашу. Приветствие. Знакомство. Прощание» дип аталган беренче дәрес, традицион рәвештә, сөйләм этикетына караган лексика һәм диалог үрнәкләре белән таныштыра. Беренче дәрестән үк игътибар сүзләрнең дөрес әйтелеше, басым мәсьәләләренә юнәлтелә, яңа лексиканы ныгыту максатында диалогларны рольләргә бүлеп уку, аларны тулыландыру кебек биремнәр тәкъдим ителә. Шунысын ассызыклау мөһим: әлеге дәреслектә, дөньяви лексика белән беррәттән, дини тематикага мөнәсәбәтле сүзләр дә урын алган: *әссәламегаләйкем, вәгаләйкемәссәлам, мәчет, ислам* һ. б.

Алга таба, 2–9 нчы дәресләрдә, телне өйрәнүчеләр сөйләмдә шактый актив булган *Бу кем? Бу нәрсә? Кайда? Кая? Кайдан? Кем белән? Нәрсә белән? Нинди? Кемне? Нәрсәне? Нишли? Нишләми?* кебек сорау

алмашлыклары һәм *кирәк/кирәкми* хәбәрлек сүзе белән танышалар. Укучының игътибары иң элек аларның грамматик табигатенә түгел, ә сөйләмдәге вазифаларына, мөмкинлекләренә юнәлтелә. Шунысы мөһим: әлеге дәрес исемнәре беренче карашка формаль-грамматик яңгырашка гына ия булсалар да, бу темаларны үзләштерү барышында телне өйрәнүчеләр *«Минем гаиләм»* [1: 14], *«Мин»* [1: 21], *«Минем дустым»*, *«Минем дус кызым»* [1: 42] текстлары, *сәгать, спорт, кибет, киемнәр* кебек темаларны үз эченә алган диалоглар, күнегүләр белән эш итәләр, яңа лексика белән танышалар. Мисал өчен, «Гаилә» темасы һәм аңа мөнәсәбәтле иң гади *әти, әни, әби, дәү әни, бабай, дәү әти, абый, апа, энем, сеңелем* [1: 11] кебек лексик берәмлекләр икенче дәрестә үк тәкъдим ителә. Әлеге дәрестә телне өйрәнүчеләр сорауны белдерүче чаралар белән дә танышалар һәм эшне «Минем гаиләм» текстын уку һәм биремнәр үтәү белән тәмамлыйлар. Ягъни беренче дәресләрдән үк телне өйрәнүчеләр диалогик һәм монологик сөйләм нигезләрен үзләштерә, шулар үрнәгендә үзләренең зур булмаган текст һәм диалогларын төзи башлыйлар. Алга таба лексика тагын да байый һәм төрләнә. Мәсәлән, «Кем белән? Нәрсә белән? Нинди?» дип аталган алтынчы дәрестә укучының игътибарына тән әгъзалары, төсләр, сыйфатларга кагылышлы сүзләр тәкъдим ителә [1: 36–38].

Уку әсбабындагы һәр дәрес сүзләрнең дөрес укылышын, әйтелешен ныгытуны максат иткән күнегүдән башлана. QR-код аша аларны тыңлау мөмкинлеге дә бар. Мәсәлән, бишенче дәреснең беренче биреме түбәндәгечә яңгырый: *«Прочитайте вслух: Өй, миннән, синнән, аңардан, кайтасың, сорыйсың, иртән, кич, көн, көндез, бүген, иртәгә, иртәнге аш, төшке аш, кичке аш, гаилә, рәхмәт»* [1: 29]. Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк: уку әсбабында аерым сүзләрнең дөрес әйтелеше-яңгырашына, сүз басымына гына түгел, ә, гомумән, җөмлә интонациясенә дә игътибар ителә [1: 19, 25, 58–59].

10–24 нче дәресләрдә кеше тормышының төрле сфераларын үз эченә алган, милли-мәдәни компонент та чагылыш тапкан *«Туган көн», «Мәктәптә», «Мәктәп ашханәсендә», «Һөнәр», «Табибта», «Фатир», «Һава торышы», «Шәһәрем», «Казан», «Авыл. Йорт хайваннары, кошлары», «Татарстан картасы», «Сәяхәт», «Телефоннан сөйләшәм», «Бакчада», «Татар халык бәйрәмнәре»* кебек темалар урын ала. Бу дәрес темалары һәм аларда тәкъдим ителгән лексик-грамматик материал ниндидер ябык системаны тәшкил итми, киресенчә, алар бер-берсен тулыландыра, үзара керешеп үрелеп килә, ягъни лексик-грамматик тема өзелеп калмый, ә алга таба үстерелә һәм дәвам ителә. Бу биремнәрдә дә ачык күренә. Мисал өчен, өченче дәрестә «Мин» текстыннан соң *Используя текст «Минем гаиләм» на стр. 14 расскажите от имени Марата о его младшей сестре и младшем брате* [1: 21] дигән бирем бар. Дүртенче дәрестә, шуның логик дәвамы буларак, *Используя тексты предыдущих уроков, составьте информацию о других членах семьи*

*Марата. Дополните текст, описывая свою семью* [1: 28] дигән күнегү урын ала.

Гомумән, китап телне өйрәнүчеләрдә коммуникатив компетенция формалаштыру максатыннан чыгып тәкъдим ителгән күнегү, биремнәрнең төрлелеге белән дә аерылып тора. Бу төрлелек эш формаларында да, биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсендә дә чагылыш таба. Уку әсбабында актив кулланылган төп эш формаларыннан түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк: тыңлау, уку, сүзлек белән эш, ятлау, диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү, язма күнегүләр. Әлеге эш төрләре сүзләрне, текстны кычкырып уку, сүзләргә басым кую, рольләргә бүлеп уку, диалогларны тулылыландыру, диалог һәм монолог төзү, диалогларны, текстларны дәвам итү, терәк сүзләр кулланып текст төзү, тәрҗемә итү, сорауларга җавап бирү, ниндидер бер тормыш ситуациясен рольләргә бүлеп уйнап күрсәтү кебек күпсанлы биремнәрдә чагылыш таба. Мисал өчен, *Придумайте небольшой текст, используя опорные слова. Азат. Укучы. Казан. Гимназия. Өченче класс. Биш дәрес. Ике сәгать утыз минут* [1: 35].

Китапта телдән сөйләмне формалаштыру гына максат итеп куелмый, ә язма сөйләмгә дә игътибар бирелә. Мисал өчен, уку әсбабында *Допишите окончания. Мин кинога бара... . Син институт... укыйсың. Азат мәктәп... бара. Ул Казан... яши. Әни мәктәп... эшли. Син шәһәрдә яши...? Апа алты... тора. Ул сигез... институт... бара* [1: 26] кебек күнегүләр аз түгел.

Уку әсбабының грамматик эчтәлегенә килгәндә, ул шактый бай, монда исемдәге сан, килеш, тартым категорияләре, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше, фигыльнең заман формалары, боерык фигыль, инфинитив, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, сыйфат дәрәҗәләре, теләк белдерү формалары һ.б. турында мәгълүмат урын алган, әмма аларны үзләштерү үзмаксат булып күзалланмый, әлеге грамматик күренешләр, чаралар телне өйрәнүчеләрдә бәйләнешле сөйләм үстерүгә хезмәт итәргә тиеш дип карала. Телне өйрәнүчеләр әлеге белемнәрен, мисал өчен, *Попробуйте рассказать о себе и своей семье: сообщите как вас зовут, сколько лет, где живёте, где учитесь или работаете, во сколько уходите и возвращаетесь; как зовут ваших близких, кем они работают. Поздоровайтесь и попрощайтесь с родителями, друзьями, коллегами, родственниками, одноклассниками; спросите как у них дела, как они поживают* [1: 28] кебек биремнәрдә өлешчә булса да файдалана алырга тиеш дип фаразлана.

Шул рәвешчә, татар телен интенсив рәвештә өйрәнүне күздә тоткан әлеге уку әсбабы, үзенең корылыш-төзелеше, лексик-грамматик эчтәлеге һәм методикасы җәһәтеннән заманча дәреслекләргә куелган төп таләпләргә, һичшиксез, туры китереп төзелгән. Китап үз укучысын табар, алга таба тагын да камилләшер һәм татар телен саклау, популярлаштыру эшендә үз өлешен кертер дип ышанабыз.

**Әдәбият**

1. Татарский: лёгкий, удобный, простой (Интенсивный курс): учебное пособие / М.М. Шакурова, Л.М. Гиниятуллина. Казань: Татар. кн. изд-во, 2026. 232 с.

***Гарипова-Хәсәншина Венера Мәэмүн кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы мөдире*

***Гарипова-Хасаншина Венера Макмуновна,***
*кандидат филологических наук, заведующий кафедрой татарского языка и национальной культуры Российского исламского института*

*gmvenera@mail.ru*